ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«28» октябрь 2020 ел № 847

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 389 номерлы "Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 389 номерлы "Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 389 номерлы карары белән расланган «Хезмәт законнарын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларны үтәүгә ведомство контроле буенча чаралар үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге» дигән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo/tatarstan/ru) һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk/tatarstan/ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.Т.Мөхәммәтшина

Татартсан Республикасы
Арча муниципаль
районы башкарма комитетының
28 октябрь 2020 ел, № 847 карарына
2 нче кушымта

Ведомство контроле буенча чаралар үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге

1. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары – Мөхәмммәтшина А.Т.
2. Бухгалтер исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы – Ибраһимов А.Ф.
3. Юридик мәсьәләләр буенча бүлек башлыгы – Сәгыйтова Л.Г.
4. Хезмәтне саклау буенча белгеч – Нәбиуллин И.М.
5. Кадрлар бүлеге баш белгече – Салихова Э.И.